**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 август № 531

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 16 февраль, 59 нчы; 2006 ел, 7 июнь, 282 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 858 нче; 2009 ел, 24 февраль, 98 нче; 2010 ел, 31 март, 205 нче; 2011 ел, 10 июнь, 470 нче; 2011 ел, 13 август, 673 нче; 2012 ел, 17 август, 716 нчы; 2013 ел, 7 март, 153 нче; 2013 ел, 25 ноябрь, 924 нче; 2014 ел, 7 июнь, 387 нче; 2015 ел, 27 ноябрь, 897 нче; 2016 ел, 8 апрель, 202 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең 3.4 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.3 һәм 5.4 нче пунктлар өстәргә:

«5.3. Комитетның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү Комитет рәисе боерыгы белән расланган эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге нигезендә башкарыла.

5.4. Комитет эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча исәбеннән керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\531.docx